ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2025 елның 20 октябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлегендә Горшково авылы халык җыены

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлегендә Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләре хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә 2026 елга үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, бензотриммер, бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (киртәләр кору (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуция челтәрендәге «атарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Горшково авылы, Күл арты ур., 35а номерлы йорт янында мәгълүмат стендында, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы С.Ю.Питеркина